МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.03.2015 г.Казань № 241од

**Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) бирү өчен коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру чыгымнарын каплау максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен раслау турында” 2014 елның 12 маендагы 314 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында,

**БОЕРАМ:**

1. Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) бирү өчен коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Субсидия күләмен билгеләү тәртибен һәм мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар исемлеген расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге Боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

**Министр** **А.М. Сибәгатуллин**

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2015 елның 11 мартындагы
241 од номерлы Боерыгына
**1 нче кушымта**

# Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) бирү өчен коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) бирү өчен коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру чыгымнарын каплау максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен раслау турында” 2014 елның 12 маендагы 314 номерлы карарын (алга таба – Карар) гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

1.2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) әлеге Тәртип нигезендә сайлап алынган коммерциягә карамаган оешмаларга мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру, мәдәни мирасны, дәүләт милли сәясәтен популярлаштыру чыгымнарын каплау максатларында субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) (алга таба – субсидияләр) бирә.

## 2. Сайлап алуда катнашуга заявкалар һәм башка документлар бирү тәртибе

2.1. Заявкалар кабул итү турында белдерү Министрлыкның рәсми сайтында (http://mincult.tatarstan.ru) басылып чыга. Белдерүдә Министрлыкның документларны кабул итүне гамәлгә ашыручы структур бүлекчәсе (алга таба – Бүлек) күрсәтелә. Коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан заявкалар бирү срогы белдерү басылып чыккан көннән 10 календарь көн тәшкил итә.

2.2. Сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан Министрлыкка әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә проектларны гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирүгә сайлап алуда катнашуга язма рәвештә заявка (алга таба – заявка) һәм Карарның 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән документлар тапшырыла.

Карарның 7 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

2.3. Бүлек коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан тапшырыла торган заявкаларны һәм аларга өстәп бирелә торган документларны түбәндәге адрес буенча кабул итә: 420060, Казан шәһәре, Пушкин ур., 66/33 йорт, һәм аларны терки.

## 3. Эксперт комиссиясе

3.1. Коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алуны мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) бирү өчен коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алуны үткәрү буенча Эксперт комиссиясе (алга таба – Комиссия) гамәлгә ашыра, ул субсидияләр алу хокукы булган коммерциягә карамаган оешмаларны (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) ачыклау максатларында Министрлык каршында төзелгән коллегиаль киңәшләшү органы булып тора.

3.2. Комиссиянең кимендә 9 кешедән торган составы Министрлык боерыгы белән раслана.

Татарстан Республикасы мәдәният министры Комиссия рәисе була.

3.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

3.4. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

үз утырышларына коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләрен чакырырга, Комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча объектив карарлар кабул итү максатларында аларны үз утырышларында тыңларга;

үз эшенә мәдәният өлкәсендәге белгечләрне җәлеп итәргә;

субсидия күләмен билгеләргә.

3.5. Комиссия рәисе булмаганда, Комиссия утырышын Комиссия рәисе урынбасары үткәрә. Комиссия утырышлары, әгәр аларда Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы була.

3.6. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Министрлык башкара.

3.7. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алуга дәгъва кылучы коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан тапшырылган документлар һәм материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

## 4. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

4.1. Комиссия өстәлгән документлары һәм материаллары белән бергә Бүлеккә кергән заявкаларны аларны бирү срогы тәмамланган көннән 7 календарь көн эчендә карый.

4.2. Комиссия сайлап алуны түбәндәге критерийлар нигезендә оештыра һәм үткәрә:

коммерциягә карамаган оешма эшчәнлегендәге төп юнәлешләрнең әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән, гамәлгә ашыру өчен субсидия бирелә торган проектларга туры килүе;

матди-техник һәм кадрлар ресурсларының булуы;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырыла торган проектларның үзенчәлеге, сәнгати кыйммәте һәм актуальлеге.

Һәр критерий буенча баллар саны Комиссия тарафыннан 100 баллы шкала буенча (0дән 100гә кадәр) билгеләнә. Алынган баллар суммасы буенча коммерциягә карамаган оешмаларның рейтингы барлыкка килә.

4.3. Рейтинг нигезендә Комиссия сайлап алуда катнашуга заявкалар биргән коммерциягә карамаган оешмалар арасыннан әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән юнәлешләрнең һәркайсы буенча бер субсидия алучыны билгели. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә нигезендә 5 календарь көн эчендә субсидия бирү турында Министрлык боерыгы чыгарыла.

4.4. Беркетмәләр Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлегендә өч ел буе сакланырга тиеш.

4.5. Субсидия бирү турында боерык чыгарылган көненнән 3 календарь көн эчендә Министрлык сайтында (http://mincult.tatarstan.ru) бастырып чыгарыла.

4.6. Субсидия бирү турында Министрлык боерыгы басылып чыккан көннән 7 календарь көннән дә соңга калмыйча Министрлык субсидия алучы белән әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә расланган рәвеш буенча Килешү төзи.

Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә
ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль)
учреждениеләргә субсидияләрдән тыш)
бирү өчен коммерциягә карамаган
оешмаларны сайлап алу тәртибенә
**1 нче кушымта**

# Мәдәният өлкәсендәге проектны гамәлгә ашыру өчен субсидия бирүгә ЗАЯВКА

| | | |
|---|---|---|
| 1 | ПРОЕКТНЫҢ ИСЕМЕ (коммерциягә карамаган оешманың игълан ителгән максатларына һәм юнәлешләренә туры килергә тиеш) | |
| 2 | МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕ - КОММЕРЦИЯГӘ КАРАМАГАН ОЕШМАНЫҢ ОЕШУ-ХОКУКЫЙ РӘВЕШЕ ҺӘМ ИСЕМЕ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР (ОПФ исеме, мөрәҗәгать итүче оешманың тулы исеме) | |
| 3 | МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕ - КОММЕРЦИЯГӘ КАРАМАГАН ОЕШМА ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ АНЫҢ ГАМӘЛГӘ КУЮ ДОКУМЕНТЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ ТӨП МАКСАТЛАРЫ | |
| 4 | МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕ - КОММЕРЦИЯГӘ КАРАМАГАН ОЕШМАНЫҢ ҖИТӘКЧЕСЕ (Ф.И.Ат.Ис., гражданлыгы) | |
| 5 | МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕ ОЕШМАНЫҢ АДРЕСЫ (мөрәҗәгать итүче оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә) | |
| 6 | ПРОЕКТНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ | |
| 7 | ПРОЕКТНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ УРЫНЫ | |
| 8 | ПРОЕКТНЫҢ ГОМУМИ БЮДЖЕТЫ | |
| 9 | МӘДӘНИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ПРОЕКТНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫННАН СОРАЛА ТОРГАН АКЧА КҮЛӘМЕ | |
| 10 | ОЕШМАНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ: | |
| | ИНН/КПП | |
| | Исәп-хисап счеты | |
| | Хезмәт күрсәтүче банкның исеме һәм урнашкан урыны | |
| | Корреспондент счеты | |
| | Телефон | |

Заявканы тутыру датасы ___ ___ _____

Мөрәҗәгать итүче оешма җитәкчесенең имзасы

Мөрәҗәгать итүче оешманың баш бухгалтеры имзасы М.У.

Заявканы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына

бирү датасы ___ ___ _____

Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә
ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль)
учреждениеләргә субсидияләрдән тыш)
бирү өчен коммерциягә карамаган
оешмаларны сайлап алу тәртибенә
**2 нче кушымта**

# КИЛЕШҮ

**Казан шәһәре** **«___»__________ 20__ ел**

Бер яктан, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, алга таба “Министрлык” дип аталачак, аның исеменнән __________________ ____________________ нигезендә Татарстан Республикасы мәдәният министры ______________________________________________________ эш итә һәм, икенче яктан, ________________________________________________________________, алга таба “Оешма” дип аталачак, аның исеменнән __________________ ____________________ нигезендә ____________________________________________ эш итә, алга таба алар бергә “Яклар” дип аталачак, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү ____________________________________ ________________________________________________________________п роектны гамәлгә ашыру чыгымнарын каплау максатларында Оешмага Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Әлеге Килешү буенча субсидияләр чыгымнарның түбәндәге төрләренә җибәрелә: _____________________________________________ __________________________________________________________________ ______________________________________________________________ .

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Министрлык әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы график буенча Оешмага 20__ елның __ __________ ____ номерлы ________________________________________________________________ нигезендә __________________________________________________________________ ________________________________________________________________ак чалары исәбеннән бүлеп бирелгән _______________ күләмендәге субсидияне ________________________ исәп-хисап счетына күчерергә йөкләмә ала.

2.2. Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү өчен, шулай ук әлеге Килешүдә каралган тикшерүләрне (контроль чараларны) уздыру өчен кирәкле мәгълүматны, документларны Оешмадан соратып алырга;

- Оешманың әлеге Килешү кысаларында үзенә алган йөкләмәләрен үтәвен тикшереп торырга;

- әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүгә Татарстан Республикасы бюджеты чараларыннан бүлеп бирелә торган акчалардан максатчан файдалануны тикшереп торырга;

- субсидияләр күчерүне туктатып тору һәм туктату турында карарлар кабул итәргә;

- Оешманың әлеге Килешүне үтәвенә бәйле тикшерүләр, шулай ук башка контроль чаралар уздырырга;

- әлеге Килешүдәге йөкләмәләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр үткәрергә;

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

2.3. Оешма түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән субсидияне максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

- Министрлык таләбе буенча һәм ул билгеләгән срокларда әлеге Килешү шартларының үтәлүенә тикшерүләр яисә башка контроль чаралар уздыру өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны тапшырырга, шулай ук Министрлык шундый тикшерүләр (контроль чаралар) уздырганда аңа ярдәм итәргә;

- Килешү кысаларында проектны гамәлгә ашыруның барышы турында Министрлыкка мәгълүмат биреп торырга;

- субсидия акчаларын максатчан файдалануга бәйле чыгымнар турында Министрлыкка, беренчел бухгалтерлык документларының күчермәләре белән, хисап тапшырырга;

- проектны гамәлгә ашыру барышында субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итәргә: ____________________________________________________________.

(субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең конкрет күрсәткечләре күрсәтелә)

2.4. Оешма түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча кирәкле консультацияләр һәм аңлатмалар алырга;

- Оешманың әлеге Килешүне үтәвенә бәйле тикшерүләр (контроль чаралар) уздырганда катнашырга;

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

2.5. Әлеге Килешүне имзалап, Оешма Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Оешманың әлеге Килешүдә билгеләнгән субсидияне бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр уздыруга рөхсәт бирә.

## 1. Субсидия буенча бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалану турында хисап

1.1. Оешма әлеге Килешүнең гамәлдә булу срогы узгач бер ай эчендә Министрлыкка субсидия акчаларын максатчан файдалану һәм проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисап бирә, аның нигезендә Министрлык,

әлеге Килешүнең 2.3 пунктында билгеләнгән критерийларны исәпкә алып, субсидияне файдалануның нәтиҗәлелеген бәяли.

1.2. Субсидия буенча бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалану турындагы хисап ике нөсхәдә язма рәвештә тапшырыла.

## 2. **Субсидия күчерүне туктатып тору, туктату нигезләре һәм субсидия күләмен киметү һәм аны кире кайтару тәртибе**

4.1. Субсидия (субсидиянең калган өлешен) күчерүне туктатып тору түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

- субсидияне максатчан файдаланмау факты билгеләнгәндә;
- әлеге Килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Оешма тарафыннан хисап тапшырылмаганда.

4.2. Субсидиянең әлеге Килешүдә билгеләнгән гомуми күләме түбәндәге очракта киметелергә мөмкин:

- әлеге Килешүдә каралган чараларны башкаруга финанс лимитлары Татарстан Республикасының аерым актлары белән үзгәртелгәндә.

4.3. Әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча субсидия күчерүне туктатып тору түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән хәлләр барлыкка килгән мизгелдән 10 (ун) эш көне эчендә Министрлык Оешмага туктатып тору сәбәпләре бетерелгәнчегә кадәр субсидия күчерүне туктатып тору турында хәбәрнамә җибәрә.

Хәбәрнамәдә субсидия күчерүне туктатып торуның сәбәпләре, шулай ук субсидия күчерүне туктатып тору өчен нигез булган сәбәпләрнең бетерелүен раслый торган документларны Оешма тарафыннан тапшыру срогы, ул 30 (утыз) эш көненнән дә артмаска тиеш, катгый рәвештә күрсәтелә.

4.4. Хокук бозуларның бетерелү фактын раслый торган документлар Оешма тарафыннан тапшырылмаган очракта, Министрлык 10 көн эчендә Оешмага субсидия күчерүне туктату турында хәбәрнамә җибәрә.

4.5. Әлеге Килешүдә каралган чараларны башкаруга финанс лимитлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары белән үзгәртелгән очракта, Министрлык, Оешмага тиешле язмача хәбәрнамә җибәреп, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау күләмен берьяклы тәртиптә үзгәртә.

4.6. Әлеге Килешүнең 4.2 пунктында билгеләнгән нигез буенча субсидия күләме үзгәртелгән очракта, Яклар 10 (ун) эш көне эчендә Килешүгә, тиешле өстәмә Килешү төзеп, кирәкле үзгәрешләрне кертергә тиеш.

4.7. Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидияләр Оешма тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен Оешма тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылганда;

субсидияләр бирү шартлары Оешма тарафыннан үтәлмәгәндә;

субсидияләр Оешма тарафыннан максатчан файдаланылмаганда.

Әлеге пунктта күрсәтелгән нигезләр буенча субсидияләрне кире кайтару срогы Оешма тарафыннан бозылганда, Министрлык ул акчаларны әлеге пунктта билгеләнгән срок узган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә алу чараларын күрә.

Хисап чорында файдаланылмый калган субсидия акчалары Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Оешма тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә ихтыярый рәвештә кайтарып бирүдән баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә алынырга тиеш.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу срогы һәм Килешүне үзгәртү һәм өзү тәртибе. Җаваплылык

5.1. Әлеге Килешү Яклар имзалаган көннән үз көченә керә һәм ______________________ гамәлдә була.

5.2. Әлеге Килешү бары тик Яклар ризалыгы белән, Якларның вәкаләтле вәкилләре имзалаган, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора торган өстәмә Килешү төзү юлы белән генә үзгәртелергә мөмкин.

5.3. Әлеге Килешүнең шартларын бозу бюджет законнарын бозуга карата мәҗбүр итү чараларын куллану өчен нигез була.

## 6. Бәхәсләрне карау тәртибе

6.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә Яклар арасында килеп чыга торган бәхәсләр (каршылыклар) алар тарафыннан, мөмкин булганча, сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителә, бу хакта тиешле беркетмәләр яисә башка документлар тутырыла.

**6.2.** Бәхәсләрне (каршылыкларны) җайга салу мөмкинлеге булмаган очракта, алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

## 7. Форс-мажор

7.1. Яклар йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен, әгәр тиешенчә үтәмәү хәтәр хәлләр, ягъни әлеге шартларда гадәттән тыш һәм каршы тора алмаслык вакыйгалар (форс-мажор) аркасында булганын раслый алсалар, әгәр бу вакыйгалар йөкләмәләрне үтәмәүгә турыдан-туры сәбәп булса, җаваплылыктан азат ителәләр.

7.2. Бу вакыйгалар барлыкка килгән очракта, бер Як _____ көн эчендә бу хакта икенче Якка хәбәр итәргә тиеш.

## 8. Йомгаклау нигезләмәләре

8.1. Килешүгә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарындагы үзгәрешләр үз көченә кергән көннән бер ай эчендә Оешмага тиешле язма хәбәрнамә җибәрү юлы белән Министрлык тарафыннан берьяклы тәртиптә гамәлгә ашырыла. Килешүгә кертелгән үзгәрешләр Яклар өчен хәбәрнамәдә күрсәтелгән көннән үз көченә керә.

8.2. Әлеге Килешү, Якларның һәркайсына берәр нөсхә итеп, бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

**Якларның реквизитлары:**

| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы**<br>**Мәдәният министрлыгы** | **Оешма исеме** |
| 420015, Татарстан Республикасы,<br>Казан шәһәре, Пушкин ур.,<br>66/33 йорт,<br>Тел.: (843) 264-74-01<br>E-mail: mkrt@tatar.ru<br>ИНН/КПП 1654022036/165501001<br>ОКПО 00999754,<br>ОГРН 1021602850884 | Адрес<br>Телефон<br>ИНН/КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО |
| **Татарстан Республикасы**<br>**мәдәният министры** | **Оешма җитәкчесе**<br>**вазыйфасының атамасы** |
| **______________ И.Ат.ис.Фамилия** | **______________И.Ат.ис.Фамилия** |

Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә
ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль)
учреждениеләргә субсидияләрдән тыш)
бирү өчен коммерциягә карамаган
оешмаларны сайлап алу тәртибенә
**3 нче кушымта**

## Субсидия бирү графигы

| Субсидия бирү датасы һәм чоры | Субсидиянең күчерелә торган өлеше, сум |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2015 елның 11 мартындагы
241 од номерлы Боерыгына
**2 нче кушымта**

**Субсидия күләмен билгеләү тәртибе һәм мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар исемлеге**

Конкрет проектны гамәлгә ашыруга субсидия күләме коммерциягә карамаган оешма тарафыннан фактта игълан ителгән һәм проектта тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны каплау максатларында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы өчен расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә нигезләнгән чыгымнарның 95 процентыннан артыграк булмаган күләмдә Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) бирү өчен коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алуны үткәрү буенча эксперт комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр түбәндәге чыгымнарга җибәрелергә мөмкин:

хезмәт өчен түләү;

хезмәт командировкаларында тәүлеклек түләүләр;

хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләр;

физик һәм юридик затлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә түләү, шул исәптән элемтә хезмәтләренә, транспорт хезмәтләренә, коммуналь хезмәтләргә, мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләвенә, мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләргә, башка хезмәтләргә түләүләр;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы салым законнары нигезендә салым түләүләре;

алып-сату өчен билгеләнмәгән бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу (әзерләү);

төп чаралар һәм матди запаслар сатып алу.